Шәһәр күләмендә география фәненнән татар телендә үткүрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2025-2026 нчы уку елы
9 нчы сыйныф

Эш вакыты – 90 минут
Гомуми балл – 75

1. Хәзерге вакытта Россиядә нинди төр миграция катнашучылар саны буенча күпчелекне тәшкил итә? (2 балл)
а) эчке;
б) тышкы;
в) тышкы белән эчке миграциянең күләмнәре чагыша;
г) ачыклап булмый

2. Лена, Индигирка һәм Колыма елгалары буенда яшиләр: (2 балл)
а) эвенклар; б) чукчалар; в) якутлар; г) бурятлар

3. Түбәндәге шәһәрләрне төп функцияләре белән тоташтырыгыз (6 балл)

1. Сочи	а) тарихи-культуралы
2. Түбән Новгород	б) төрле функцияләр
3. Мурманск	в) транспорт һәм промышленность
4. Суздаль	г) промышленность һәм транспорт
5. Дубна	д) фәнни
6. Санкт-Петербург	е) курорт

4. Россиядә кеше саны буенча уртача саналган шәһәрләрдә кеше саны (2 балл)
а) 20 меңгә кадәр; б) 50 меңгә кадәр; в) 100 меңгә кадәр; г) 500 меңгә кадәр

5. Түбәндәге утрауларны тиешле субъектлар белән тоташтырыгыз (4 балл)

1. Врангель утравы	а) Архангельск өлкәсе
2. Яңа җир утравы	б) Сахалин өлкәсе
3.Төньяк җир утравы	в) Красноярск крае
4. Курил утраулары	г) Чукотка АО

6. В.Беринг «Изге Петр» корабында йөзгәндә нинди утрауны ачкан? (2 балл)
а) Кадьяк; б) Кунашир; в) Медвежий; г) Врангель

7. Регионнарны мәйдан күләме арту нигезендә урнаштыр
(бердән дурткә кадәр) (4 балл)
а) Якутия (Саха); б) Адыгея; в) Мәскәү өлкәсе; г) Архангельск өлкәсе

1.	
2.	
3.	
4.	

8. Россиядә нинди транспорт төре иң аз йөк ташуы белән билгеле (2 балл)
а) автомобиль;
б) эчке су транспорты (диңгез һәм елга);
в) үткәргеч торба транспорты;
г) тимер юл

9. Химик сүс эшкәртү буенча алга киткән 3 шәһәрне сайлап ал? (3 балл)
а) Клин; б) Салехард; в) Тверь;
г) Кызыл; д) Энгельс; е) Кировск

10. Төсле металлургия буенча алга киткән 3 шәһәрне сайлап ал? (3 балл)
а) Череповец; б) Красноярск; в) Липецк;
г) Братск; д) Норильск; е) Түбән Тагил

11. Суднолар төзү буенча алга киткән 3 шәһәрне сайлап ал? (3 балл)
а) Астрахань; б) Яшел Үзән; в) Санкт-Петербург;
г) Киров; д) Свердловск; е) Владимир

12. Регионнарны көнбатыштан көнчыгышка таба урнаштыр (4 балл)

а) Иркутск өлкәсе	
б) Алтай республикасы	
в) Курск өлкәсе	
г) Пенза өлкәсе	

13. Кайсы регион Мәскәү өлкәсе белән күрше түгел? (2 балл)
а) Тверь өлкәсе; б) Ярослав өлкәсе;
в) Иванова өлкәсе; г) Владимир өлкәсе

14. Файдалы казылмаларның табылу регионнарын тоташтырыгыз
(4 балл)

1. Вольфрам һәм молибден	а) Бурятия
2. Кургаш	б) Башкортостан
3. Полиметалл	в) Төньяк Осетия
4. Бакыр	г) Саха

15. Кәгазь, картон һәм целлюзоза җитештерү буенча Казан шәһәренә иң якын урнашкан комбинатны атагыз. Бу комбинат Россиянең кайсы регионында һәм шәһәрендә урнашкан? (9 балл).

*Җавап:*_____

_____

_____

16. Совет властеның беренче бишьеллык чорында төзелгән тимер юл магистрале мамык, җиләк-җимеш үстерү төбәге белән бодай, агач, ташкүмер һәм корыч җитештерелә торган регионны тоташтырган. Бу тимер юл ничек атала? (7 балл).

*Җавап:*_____

17. Бу ярымутрау зур түгел, ләкин анда тимер рудасы запасы бик күп. Дөньяның бер урынында да файдалы казылма андагы шикелле өстә ятмый. Аны бары тик берничә метр калынлыгындагы өске катлам гына каплап тора. Әлеге ярымутрау зур ярымутрауның бер өлешен генә тәшкил итә һәм ике диңгез суы белән юыла.
Бу нинди ярымутрау? Ул үзе кайсы ярымутрауга карый? (8 балл).

*Җавап:*_____

_____

18. Россиядә уран промышленносты нык үсеш алмаган дип әйтсәк без хаклы булырбызмы? Килешсәгез, яисә башкача фикердә булсагыз, сайлаган вариантны мисаллар белән аңлатыгыз. Илебез буенча бу тармакның географиясе белән бәйле булган белемнәрегезне күрсәтегез

(8 балл)